# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Наратлы-Кичү авыл җирлегенең Исәнгол торак пунктында
2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**18 ноябрь 2024 ел** **№ 6**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлегенең Исәнгол торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы -Кичү авыл җирлегенең Исәнгол торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, 90 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар,СВОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, 1 һәм 2 төркем инвалидлар, күп балалы гаиләләрдән тыш 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2.Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Батыршин урамы буенча Исәнгол торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

3.Әлеге карарны Наратлы -Кичү авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Наратлы-Кичү авыл җирлеге башлыгы Вәлиев И.М.